**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**БОЕРЫГЫ**

31.03.2026 № 133

**Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү территориаль ярдәмче системалары идарә органнары һәм көчләре өчен гадәттән тыш хәл режимы кертү турында**

«Түбән Кама нефтехим» гавами акционер җәмгыятендә җитештерү объектындагы шартлау нәтиҗәсендә 2026 елның 31 мартында Түбән Кама шәһәрендә килеп чыккан гадәттән тыш хәлнең нәтиҗәләрен бетерү максатында, «Халыкны һәм территорияләрне табигать һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә:

1. Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү территориаль ярдәмче системалары идарә органнары һәм көчләре өчен 2026 елның 31 мартыннан, махсус боерык чыкканга кадәр, гадәттән тыш хәл режимы кертергә һәм төбәк дәрәҗәсендә чаралар күрелергә тиешлеген билгеләргә.

2. Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

гадәттән тыш хәл режимында эшләгәндә Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү территориаль ярдәмче системалары идарә органнары һәм көчләре эшчәнлеген координацияләүне;

әлеге боерыкны үтәгәндә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмаларның гамәлләрен килештерүне.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министрына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН